Китап укырга - пластик карта белән // Шәһри Чаллы. – 2025. – №38 (28 май). – Б. 5.

# Китап укырга - пластик карта белән



**К Май ае - елның бәйрәмнәргә бай чоры. Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә дәүләт тарафыннан мәдәни кыйммәтләрне саклау һәм арттыруда китапханәләрнең бәяләп бетергесез ролен тану буларак 1995 елдан гамәлгә кергән 27 май - Бөтенроссия китапханәләр көне билгеләп үтелә.**

Китапханә... Бүгенге көндә фәндә әлеге сүзнең гасырлар дәвамында формалашкан йөзләгән билгеләмәсе бар. Ләкин китапханәләрнең кеше тормышындагы ролен, асылын бер генә атама эченә сыйдырып буламы икән ул? Минемчә, юктыр.

Чөнки аларда гына барлык төр мәгълүмат, үткән тарихыбыз, олысына да, кечесенә дә ярдәмгә килерлек киңәшләр урын алган. Әгәр китаплар сакланмаган булса, галимнәребез, язучыларыбыз үзләренең ачышларын китап битләренә язып шәкертләренә өйрәтеп калдырмаган булса, тарихыбыз турында да кеше сөйләгәннәрдән генә күп мәгълүмат алып булмас иде. «Үткәне булмаган халыкның, киләчәге дә юк», - дип юкка гына әйтмәгән шул борынгылар. Китапханә ул - бер буыннан икенче буынга калдырылган рухи мирас. Бар да үзгәрә: кешелек, дәүләтләр. Ә китап - мәңгелек!

Шәһәребез Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының бүгенге көненә күз салабыз икән, ул шәһәребезнең барлык бистәләренә урнашкан 18 китапханәне берләштерә (2 - балалар һәм өлкәннәр өчен үзәк китапханәләр, 7 - балалар китапханәсе, 11 - өлкәннәр өчен махсус эшләүче китапханәләр)

Китап фондына килгәндә, 2024 ел йомгакларына күз төшерсәк, китапханәләрдә барлыгы 734мен 179 данәдә китап исәпләнә. Шуларның 605 мең 866 данәдә урыс телендә булса, 124 мең 862 данәдә татар телендә. Аудио-видео, электрон китаплар да 5 мең данәдән артык. Шуларга өстәп китапханәгә 138 исемдә газета-журналлар алдырабыз.

Бүгенге китапханәләр - китаплар саклау, китап алып укый торган урын гына түгел. Бу - даими рәвештә үткәрелүче белемне арттыра торган төрледән- төрле әдәби фестивальләр, бәйгеләр, кичәләр, очрашулар, экскурсияләр, КВН, акцияләр, квиз, квест уеннар, РК проектлар һ.б. һәм һәрвакыт гамәлдә булган тематик күргәзмәләр белән чын мәгънәсендәге мәдәни үзәк булып тора.

Китапханәчеләр бүген яна иҗади эзләнүләр чорында. Алар тарафыннан Россия, республика күләмендә күпсанлы грантлар языла, җиңүләребез байтак. Шәһәр балалар китапханәсе шул грант ярдәме белән яңартылын, модель китапханә булып ачылды. Нәтиҗәдә ул хәзерге көн таләпләренә җавап бирә торган мәгълүмати-мәдәни һәм аралашу үзәгенә әверелде. Башкача булуы да мөмкин түгел, чөнки бүгенге замана баласын «Менә бу кызыклы китап, укы әле шуны», - дип кенә китапханәгә җәлеп итеп булмый. Хезмәткәрләр елдан-ел белемнәрен камилләштерү курслары үтәләр, нидер эзләнергә, яңалык уйлап табарга тырышалар.

Шәһәребезнең бик күп китапханәләре заманча технологияләр белән җиһазландырылган, анда килүчеләр өчен компьютер бар, ул Интернет челтәренә тоташтырылган. Бүгенге көндә Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китапханәләрендә саклаучы китапларны, Татарстанның җыелма китапханә электрон форматка күчерү буенча зур эш алып барыла.

Шуларга өстәп, китап укучыларны хәзерге көндә гомум укучы билетына күчерү дәвам итә. Ул пластик карта. Безнең укучыларыбыз, бу карталар белән лык почмакларында китапханәләр хезмәтеннән файдалана ала.

Халкыбыз гомер-гомергә китап укырга яраткан. Заманында китап уку буенча илебезнең беренче урында торган чаклары да булган бит. Электән үк халыкны китапханәгә китапханәченең җылы карашы, ягымлы аралашуы тартып китергән. Ул хәзер дә шулай, бүген әлеге һөнәр ияләре үзләренең бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Шул уңайдан без дә алар- ның игелекле эшләрендә уңышлар, китапханәләргә беркайчан да сукмаклар өзелмәвен телибез.

Китап кеше язмышында зур урын тота. Китап - язма тарих, китап - халык хәтере, китап - белем чишмәсе. Китаплар - бүген дә тормышыбызның алыштыргысыз юлдашы. Китап кешедә күркәм сыйфатлар, батырлык, ихтыяр көче тәрбияли, үткәнне онытмаска, тормышның кадерен белергә, киләчәкне күрергә өйрәтә.